

# КАЛӘМ ТИБРӘТҮЧЕЛӘР

**№9 МАЙ 2020 ел**

***<u>98 нче татар – рус урта гомуми белем бирү мәктәбе</u>***



**Бөек Җиңү көне мөбарәк булсын!**

Кадерле Бөек Ватан сугышы һәм тыл ветераннарын, сугыш чоры балаларын Бөек Җиңүнең 75 еллыгы белән тәбрик итәбез! Җиңү көне безгә миллионнарның каны һәм җаны бәрабәренә яулануы белән бөек, изге һәм кадерле. Сугыш тәмамлануына 75 ел үтсә дә, хәтер яши, хәтер мәңгелек. Ватан өчен дәһшәтле көрәштә кан койган ветераннарның яралары да гомерлек. Тән яралары төзәлсә дә, җан яраларының сыкрауларын, газиз ирләрен яу кырында югалткан тол калган хатын-кызларның сулкылдауларын, ә сугыш елы балаларының әрнү-сагышларын онытырлык түгел… Бүген без алар алдында баш иеп, тиңдәшсез батырлыкларына, рухларының ныклыгына сокланабыз, алар белән горурланабыз!

Хөрмәтле сугыш һәм тыл ветераннары, хөрмәтле сугыш чоры балалары! Ил өчен барган данлы көрәш елларында күрсәткән батырлыкларыгыз, көчле ихтыярыгыз, тыныч тормыштагы фидакарь хезмәтегез, туган җиргә көчле мәхәббәтегез һәм бүгенге якты тормышыбыз өчен сезгә олуг рәхмәтебезне белдерәбез. Ватаныбызны өзелеп яраткан данлы буын вәкилләренә карата ихтирам-хөрмәтебез чиксез зур. Беркемнең дә, беркайчан да бу дәһшәтле сугыш фаҗигаләрен онытырга хакы юк. Сезгә сәламәтлек, гаилә иминлеге телибез. Дөньялар тыныч булып, иминлектә балаларыгыз, оныкларыгызның кадер-хөрмәтендә яшәргә Ходай насыйп итсен!
Бөек Җиңү көне мөбарәк булсын!

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Алтын-көмеш яуган җирдән туган-үскән ил артык**

## Бөек Җиңү

1941 нче елның 21 нче июнендә фашист илбасарлары илебезгә басып керәләр. Халкыбыз, бердәм булып, көрәшкә күтәрелә. Яп-яшь егетләр һәм кызлар туган җирне саклау өчен фронтка китәләр. Аларның күпчелеге дәһшәтле сугыш кырларыннан әйләнеп кайта алмый, туган илнең азатлыгы өчен батырларча һәлак булалар. Халкым күп авырлыкларга түзеп, бихисап батырлыклар кылып, 1945 нче елның 9 нчы маенда җиңү яулый. Бу көн иң сөенечле көннәрнең берсе була. Кешеләр җиңү шатлыгыннан урамга чыгалар. Әлеге көнне хәтта бер-берсен белмәгән, бер-берсе белән таныш булмаганнар да кочаклаша, күрешә, бәйрәм белән котлаша. Шушы вакыттан 9нчы Май дәүләт бәйрәме һәм ял көне дип игълан ителә.

Әйе, быел сугыш тәмамланганга 75 ел! Бу зур дата һәм тантаналы бәйрәм! Ничә еллар үтсә дә, безгә азатлык һәм тынычлык алып килгән ветераннарыбызны без кадерләргә һәм онытмаска тиешбез!

**7Б сыйныф укучысы Халилова Нармин**



**Беркем дә, бернәрсә дә онытылмый!**

Туган өен белмәгән

Туган авылын белерме?

Туган авылын белмәгән

Туган илен белерме?

(мәкаль)

Дөрестән дә, һәркем үзенең туган авылы һәм аның күренекле кешеләре турында белергә тиеш. “Үткәнен оныткан халыкның киләчәге юк”, - диләр бит. Һәрбер кешенең үз яшәү тарихы, үз язмышы бар. Тамырларың – туганнарың, әби-бабайларың турында яңа мәгълуматтан хәбәрдар булу бик кызык. Әмма иң кызыгы – бөек шәхесләр, геройлар – Бөек Ватан сугышында катнашучылар турында белү. Әлеге кешеләр – чын мәгънәсендә каһарманнар, курку белмәс, Ватаннарына тугры булып калган кешеләр. Аларның күпчелеге яу кырыннан әйләнеп кайтмаган.

Сугыш һәрбер йортның диярлек бусагасын атлап кергән һәм иң яхшыларның яхшыларының гомерен өзгән. Безнең Татарстаннан гына да фашизмга каршы сугышка 700 меңнән артык кеше киткән. Шуларның яртысы диярлек туган нигезләренә әйләнеп кайтмаган. Әниләр- улларын, ирләрен, кызлар- сөйгән ярларын, балалар аталарын югалткан. Шуңа күрә, 9 Май- Җиңү көне ветераннарыбыз өчен шатлыклы да, бер үк вакытта моңсу да бәйрәм.

Без күп корбаннар бәрабәренә яулап алынган бүгенге тормышның кадерен белергә, Ватаныбызны яратырга, сугышның бар авырлыгын үз җилкәсендә күтәргән ветераннарыбызны хөрмәт итәргә, аларга кирәк чакта ярдәм итә белергә тиешбез.

Картаймагыз әле, ветераннар!

Европаны яулап алган ирләр!

Хәтерлиләр әле Сезне бик күп язлар!

Хәтерлиләр әле Сезне бик күп көзләр!

Картаймагыз әле ветераннар,

Картаймагыз, әй тынгысыз җаннар!

Сезгә тиеш әле бик күп язлар,

Сезгә тиеш әле бик күп назлар.

**югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Табигатьне саклыйк!**

Туган җир, туган як, туган туфрак! Әти-әни кебек бик тә якын һәм кадерле бу сүзләр! Кеше үзенең туган ягы белән горурланганда, иң элек, аның табигате, уңган-булган кешеләре турында сөйләргә ярата. Аңа багышлап шигырьләр, җырлар иҗат итә. Бу, чыннан да, шулай. Һәр кешегә үзенең туган ягының табигате иң матуры, иң гүзәле булып тоела.
Саф һавасы да күңелгә шифа булып ята.



Табигать безгә елга-күлләрне, урманнарны, чишмәләрне, болыннарны бүләк иткән. Шушы байлыкның кадерен белеп яшәсәк иде.

Табигатьне саклый белик, дуслар,

Чүп-чар атмыйк тирә-юнебезгә.

Яшеллеккә күмелгән май ае да

Шатлык өсти безнең күңелебезгә!

**5Б сыйныф укучысы Касыймов Инсаф**

**7Б сыйныф укучыларының Җиңү көненә багышланган хезмәтләре**





**Ющенко Эвелина** **Верниковский Арсений**







**Осипченко Арина** **Замалеева Луиза**

**Кадерле Дәү бабаем!**


Быел Бөек Җиңүгә 75 ел тула. Шул уңайдан мин әбием белән аның әтисе Илшат бабай турында сөйләшеп утырдым. Ул сугыш ветераны булган. Фронтка сугышның беренче көннәреннән үк киткән. Брест шәһәре янында сугышкан. Курск янында бабай авыр яраланган. Елга якын госпитальдә яткан. 1944 нче елда 1 группа инвалид булып авылга кайткан. Әбием белән өч кыз тәрбияләп үстергәннәр. Менә шундый хатирәләр белән уртаклашты әбием. Рәхәтләнеп сөйләшеп утырдык.

Рәхмәт инде хөкүмәткә! Дәү бабамның каберенә ак мәрмәрдән таш куйдырды. Урының җәннәттә булсын, Дәү бабам!

**8А сыйныфы укучысы Айметдинова Эльвина**

**Дәү әтием-горурлыгым!**

9 май көнне Бөек Ватан сугышының тынганына 75 ел була. Сугыш, дип әйтүгә, минем күз алдыма җимерелгән йортлар, ятим балалар килеп баса. Яшь-яшь егетләр, кызлар туган җирләрен саклау өчен, фронтка киткәннәр. Туган илебезне саклау өчен, алар гомерләрен дә кызганмыйча көрәшкәннәр.



Шундыйларның берсе- минем Дәү әтиемнең әтисе Зыков Кузьма Григорьевич.Ул 1924 елда Кайбыч районы Мэльки авылында туган. Бөек Ватан сугышында 1942 нче елдан алып 1945 нче елга кадәр булган. 1945 нче елда сугыш тәмамланса да, ул туган илебезгә 1947 нче елда гына кайта алган. Дәү әтием туган илебезне саклар өчен кулыннан килгәннең барысын да эшләгән. Дәү әтием-минем горурлыгым!

Сугыш бетүгә 75 ел булуга да карамастан, безнең Дәү әтиләребезгә һәм ветераннарыбызга карата булган хөрмәт беркайчан да сүрелмәячәк. Аларны без гомер буе олылап, хөрмәт итеп яшәячәкбез. Бәйрәм белән сезне, хөрмәтле ветераннарыбыз!

**7Б сыйныф укучысы Иванова Виктория**

***Батырлык турында мәкальләр***

Батырлык яуда беленер.
Батыр бер үләр, куркак көн дә үләр.
Батыр-илнең казыгы.
Батыр егет-ил күрке.
Батыр үзе үлсә дә, даны үлми.
Батыр ут булыр, куркак юк булыр.
Батырга таяк та корал.
Батыр башлап җибәрә, аннан мең кул иярә.
Батыр үз халкын яклый.
Батырлыкта - матурлык.
Батырлыгыңны мәйданда сынат.

Шулай ук май ае безнең ***Рамазан ае*** буларак та билгеле. Рамазан ае- ул сабырлык ае, сабырлыкның бүләге- җәннәт, бу ай изгелек һәм мәрхәмәтлелек ае. Шул уңайдан сезгә ***ихлас теләкләребезне*** җиткерәбез!

Юлыңда нинди генә кыенлыклар,
борчу-хәсрәт, югалтулар,
күз яшьләре очрамасын-Бер үтенеч сиңа.
Түзем бул! Тешеңне кысып яшь аралаш елмай!
Аягыңа бас! Аллаһыбыз тик яраткан бәндәләрен генә сыный!

Тукран тукылдарга туган,
Сандугач сайрар өчен!
Яшим диеп яшәсәнә-
Салып бар җаның көчен!

Үткән тормышка бәйләнмәгез.
Үпкәләп, ачу саклап яшәмәгез.
Бер кешедән дә көнләшмәгез!

Урлашма... Кешенекенә кызыкма!
Һәрвакытта да үз юлың, үз фикерең,
үз кыйблаң булсын! Күңелеңдә
изгелеккә урын ач!






**Редколлегия:**

**Касыймова Гөлнур Наил кызы**

**Әмирхан Еники, 23.**
**Тел: 8 (843) 236-24-12**
**Сездән язмалар көтеп калабыз!**